# КАРАР
## Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге составына керүче Пионер авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

28 ноябрь 2023 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы» Мюд авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы 24 ст, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советы карары белән 05.11.2019 № 99 «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында», карары белән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, 2023 елның 28 ноябрендә Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Пионер авылында түбәндәге сорау буенча узды::« Сез 2024 елда Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Пионер авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә ,( I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш), алынган акчаларны җирле әһәмияттәге сорауларны хәл итүгә ,түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә ризамы:

Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

- Пионер бистәсе чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау (вак таш сатып алу, кышкы чорда юлларны кардан чистарту-килешү буенча эш өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)

Күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы рәвештә торак пункт территорияләрен төзекләндерүне оештыру

- Пионер бистәсе территориясен төзекләндерү (трактор һәм аларга комплектлау өчен асмалы җиһазлар сатып алу)

«РИЗА» «КАРШЫ» «ТЫЕЛДЫМ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 84 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 60 граждан.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән::

Риза" позициясе өчен 45 граждан тавыш бирде;

"Каршы" позициясе өчен 15 граждан тавыш бирде.

"Тыелдым"позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бу нигездә, гражданнар җыены КАРАР итте:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Мюд авыл җирлегенең Пионер авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга

2. Сорау буенча карарны кабул дип танырга: ::« Сез 2024 елда Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Пионер авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә ,( I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш), алынган акчаларны җирле әһәмияттәге сорауларны хәл итүгә ,түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә ризамы:

Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

• Пионер бистәсе чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау (вак таш сатып алу, кышкы чорда юлларны кардан чистарту-килешү буенча эш өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)

Күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы рәвештә торак пункт территорияләрен төзекләндерүне оештыру

• Пионер бистәсе территориясен төзекләндерү (трактор һәм аларга комплектлау өчен асмалы җиһазлар сатып алу)

3. Әлеге карарны Мюд авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
ТР Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге башлыгы Т.В. Зюзина